Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№10 (103)

3 апрель 2014 ел




# Без җаваплы да, шаян да!

Ни генә әйтсәгез дә, студент еллары иң күңелле һәм истә кала торган вакыт. Моңа, әлбәттә, мин үзем студент булгач инандым. Аеруча КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында белем алучы студентларның тормышы кызыгырлык.

## Вакыйгалар эзеннән

**2 АПРЕЛЬ** көнне ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТ**ның чираттагы **УТЫРЫШЫ УЗДЫ**.

Беренче булып, һәрвакыттагыча, Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше белән таныштырды. Яңа уку елыннан беренче курсларны инглиз теленнән көчәйтелгән программа буенча укыту башланачак. Студентлар өченче курстан лекцияләрне инглиз телендә тыңларга тиеш булачак. Бу фикерне ректор КФУ делегациясенең АКШка булган визитына бәйләп әйтте. Шушы көннәрдә уку йорты җитәкчелеге делегациясе Пенсильвания штаты университетында булды. Алар кара алтын-газ, инженерия, икътисад, энергетика һ.б. өлкәләр буенча алдынгы галимнәр белән очрашты. Ике арада үзара хезмәттәшлек итү буенча килешүләр төзелде. Алга таба 2014/2015 уку елына кабул итү кампаниясенә әзерлек турында Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** сөйләде, апрель аенда абитуриентларны җәлеп итү өчен уздырылачак чаралар турында мәгълүмат бирде, Таҗикстан Республикасына булган визит нәтиҗәләре белән дә таныштырды. Ректор чит ил студентларын аспирантурага җәлеп итү максатын да куйды. Алар өчен махсус шартлар булдырылачагы турында да әйтте. Фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.НУРГАЛИЕВ** КФУның кара алтын-газ-химия комплексы өлкәсендә булган перспективалы эшләнмәләре турында чыгыш ясады. Төрлеләрдә мәгълүматлаштыру һәм элемтә департаменты директоры **Д.БУРМИСТРОВ** структур бүлекчәләрнең компьютер техникасы белән җиһазландырылуы һәм аларны сакланышы турында мәгълүмат җиткерде. Тышкы элемтәләр департаменты директоры **А.КРЫЛОВ** «Россотрудничество» эгидасы астында уза торган халыкара мәгариф күргәзмәләре турында хәбәр итте.

• • • •

**18-28 МАРТТА** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының С.Сәйдәшев ис. Югары сәнгать мәктәбендә фортепиано сәнгате һәм «Art of Piano» осталыгы буенча укучыларның **III БӨТЕНРОССИЯ** читтән торып үткәрелә торган **ОЛИМПИАДАСЫ УЗДЫ**. Быел олимпиадада Россиянең төрле төбәгеннән 72 яшь пианист катнашты. Нәтиҗәдә олимпиаданың җиңүчеләре билгеләнде, укучыларның һәммәсенә катнашучы димпломнары тапшырылды.

• • • •

**25-27 МАРТ** көнне Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында **КФУ** студентлары **«ШЛЮМБЕРЖЕ»** нефть сервисы компаниясе **ВӘКИЛЛӘРЕ** белән **ОЧРАШТЫ**. Чарада студентлар «Шлюмберже» турында тулы һәм тәфсилле мәгълүмат алды. Сайлап алу турлары вакытындагы тестлаштыру һәм әңгәмә нәтиҗәләре буенча якын арада КФУ студентларына шәхси тәкъдимнәр киләчәк.

• • • •

**28 МАРТТА** Яр Чаллы институтында Яр Чаллы Башкарма комитеты белән берлектә оештырыла торган балалар һәм яшьләр гаммәви мәгълүмат чараларының **«МЕДИАПОКОРЕНИЕ» V БӨТЕНРОССИЯ ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ**. Барлыгы 250 гариза кабул ителгән иде. Фестиваль бүләкләү тантанасы белән тәмамланды. Фестивальнең президенты Яр Чаллы мэры Васил Шәйхразиев Г.Акыш исемендәге лицей-интернатының «Илһам» газетасына махсус бүләген тапшырды. Ә төп җиңүче һәм «МедиаПокорение» фестиваленең Гран-при иясе дип Зәй «Балалар иҗаты йорты»ның «Лестница» газетасы табылды.

• • • •

**31 МАРТТА** КФУда укучыларның Н.И.Лобачевский исемендәге **XV ИДЕЛ БУЕ ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ ЯБЫЛУ ТАНТАНАСЫ БУЛЫП УЗДЫ**. 28-31 март көннәрендә 8-11 сыйныф укучылары искиткеч нәтиҗәләргә ирештеләр. 26 номинациядә 200дән артык катнашучы төрле дәрәҗәдәге грамота белән бүләкләнде. Җиңүчеләр арасында Н.И.Лобачевский исемендәге лицейдан 9, һәм КФУ IT-лицееннан 4 укучы бар. Җиңүчеләрне котлыйбыз!

• • • •

Яр Чаллы институтының икътисад теориясе һәм икътисад сәясәте кафедрасы мөдире **А.МАКАРОВ** «Казахстан-2050» стратегиясе һәм СНГ илләре милли икътисадының көндәшлеккә сәләте мәсьәләсе» **VI ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯДӘ КАТНАШТЫ**. Бирегә Казахстан, Россия һәм Украинаның 26 югары уку йортыннан галимнәр җыелган иде. Чарада А.Макаров «Россия икътисадының инновацион үсеше контекстында мәгариф реформасы» дип исемләнгән доклад белән чыгыш ясады.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Тел белгән – ил гизгән

# Гыйлем ашарга сорамас, ашарга бирер!

Дания ФАТЫЙХОВА

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында халыкыбызның төрле катлам вәкилләре өчен янәдән бушлай татар теле курслары эшли башлады.





Быел алар 1 апрельдә башланып, июнь азагына кадәр дәвам итәчәк. Проект ТРның Министрлар Кабинеты булышлыгы белән гамәлгә ашырыла.

Курслар моннан ике ел элек барлыкка килә һәм дәресләрдә татар телен өйрәнергә теләүчеләр саны бик күп була: меңнән артып китә. Укыту эшләре тиешле югарылыкта башкарылганга, укучылар бик канәгать калалар һәм аларның күбесе татар телен өйрәнүләрен икенче елда да дәвам итәләр. Узган ел шәкертләрнең саны кимрәк булган. Моны 2013 елда ТР Президенты Р.Миңнеханов йөкләмәсе буенча гамәлгә ашырылган уникаль проект – «Ана теле» онлайн-мәктәбенең эшли башлавы белән аңлаталар. Быел исә татар теле белән кызыксынучылар саны шактый зур икән.

Дәресләрне Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә эшләүче, курсларда укыту юнәлешендә тәҗрибәле булган, югары класслы белгечләр алып барачак. Әлеге бүлек җитәкчесе Әлфия Шәүкәтовна сүзләренчә, быелгы курсларда чит ил вәкилләре дә бар икән. Төркия, Кытай, Казахстан, хәтта Америкада татар телен өйрәнергә теләк белдергән. Мисал өчен, Гари Гуадагноло – Көньяк Каролина университеты аспиранты – берничә ел элек институтта татар телен өйрәнгән булган. Хәзер ул янәдән, фәнни тикшеренү үткәрү өчен, Казанга кайткан һәм курсларда татар телен камилләштерергә уйлый икән.

28 март көнне институтта курсларда укырга теләүчеләр белән оештыру җыелышы булды. Анда шәкертләр институт җитәкчелеге һәм курсны оештыручылар белән күреште, кызыксындырган сорауларын бирде. Укытучылар укучыларны курсның программасы, укыту ярдәмлекләре, уку төркемнәренә бүлү үзенчәлекләре белән таныштырды. Шулай ук дәресләрне оештыру һәм уздыру, курслар тәмамланганда контроль тест үткәрү һәм сертификат алу мәсьәләләре турында да фикер алыштылар. Дәресләр вакытын шәкерт үзе сайлый: укулар иртән, көндез, кич белән дә булырга мөмкин. «Ана теле» проекты методисты Нәзифә Мигъманова сүзләренчә, быел курсларга җәмгыятебезнең төрле катлам вәкилләре: мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар, инженерлар, җитәкчеләр гариза юллаган. Шулай да, күпчелекне пенсионерлар тәшкил итә икән.

Уку ике төркемдә алып барылачак: татар телен башлап өйрәнүчеләр һәм дәвам итүчеләр. Уку форматына килгәндә, басым күбрәк коммуникатив метод – сөйләмгә ясалачак. Шулай ук төрле фильмнар карау, экскурсияләр оештыру һ.б. планлаштырыла.

• Мәрхәмәтлелек



# Кунакта – ветеран укытучылар!

Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ, Укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы җитәкчесе, профессор

Җир йөзендә кызыклы, мөһим, кирәкле һөнәрләр аз түгел. Шулар арсында укытучы һөнәре аерым урынны тота. Аяусыз еллар хәтердәге елларны һәм вакыйгаларны оныттырса да, беренче укытучының җылы карашы, ягымлы елмаюы безне гомер буена озата бара.

КФУның Психология һәм мәгариф институтына Яшел Үзәннән килгән ветеран укытучылар хакында да бары тик яхшы сүзләр генә сөйләп була: РФ һәм ТРның атказанган укытучылары, мәгариф алдынгылары Н.Т.Тулпарова, А.А.Садриев, Т.А.Мастеркова, М.Х.Вазыхова, Л.Т.Рәхмәтуллина, Ф.А.Газизоа, Д.Г.Афанасьева. Бүген дә ярсулы вакыт ташкынында алар ярата, тыңлый, күрә белү, яңаны, мәгънәлелекне, искитәрлекне генә сайлап алып, тоя белү сәләтен җуймаганнар.

Очрашу ике яклы сөйләшү рәвешендә узды. Ветераннар матур итеп бизәлгән дипломнар белән бүләкләнде, аларга КФУның мәгариф эшчәнлеге белән таныштыра торган мәгълүмати материаллар тапшырылды. Заманча педагогиканың актуаль мәсьәләләре хакында профессорлар Җ.Г.Нигъмәтов, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Л.Н.Нугуманова сөйләде. Доцент Р.М.Галиева кунакларны педагогик белем бирү музее экспонатлары белән таныштырды.

Көннең икенче яртысында ветераннарга күңел ачу программасы тәкъдим ителде. Алар татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри музеена бардылар, Г.Камал театрында «Кыю кызлар» музыкаль комедиясен карадылар. Педагогика һәм мәгариф институты директоры А.М.Кәлимуллин әйтүенчә, ветеран укытучылар белән мондый эчтәлекле һәм кызыклы очрашулар уку елы азагына кадәр үткәреләчәк.

• Иҗат үре

# Киездән ясалган шедеврлар күргәзмәсе

Галия СӘЛИМОВА

Шушы көннәрдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Манзара» күргәзмәләр залында «Сәләтле яшьләр. Мәктәп – ВУЗ» проекты кысаларында С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбе Дизайн кече академиясе каршындагы Кукмара балалар сәнгате мәктәбенең «Могҗигалы киез дөньясы» дип исемләнгән күргәзмәсе ачылды.







Ачылыш тантанасында ФһМБИ директоры Р.Җамалетдинов, С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбе мөдире З.Явгильдина, сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы мөдире Р.Сәлахов, Кукмара районыннан килгән кунаклар – Кукмара районы мәгариф идарәсе башлыгы Р.Мансуров, Дизайн кече академиясе мөдире Л.Низамов, Кукмара балалар сәнгате мәктәбе директоры Д.Рафиков бар иде.

Күргәзмәдә Дизайн кече академиясендә белем алучыларның киез басу техникасында эшләнгән сюжетлы паннолары, уенчыклары, костюмнары, аксессуарлары, киез итекләре тәкъдир ителде. Укучылар тәҗрибәле педагоглары җитәкчелегендә киез басуның борынгы техникасы ярдәмендә чып-чын шедеврлар тудыралар. Киездән ясалган һәр эшләнмә уникаль, чөнки ул үзенә ясаучының җан һәм кул җылысын сеңдергән. Дизайн кече академиясендә укучыларның иҗади уңышлары хакында Халыкара, Бөтенроссия һәм республика күләмуздырылган декоратив-кулланма сәнгать һәм дизайн конкурсларында яуланган соңгы җиңүләре дә сөйли.

• Бездә кунак бар

# «Румб»лылар сәяхәте

Рөстәм ФӘРХУЛЛИН, Экология һәм география институты ассистенты

Экология һәм география институтыдагы географик һәм экологик белем бирү бүлегендә эшләп килә торган «Җиде румб» турклубы актив эшчәнлек алып бара, төрледән-төрле очрашулар оештыра.

Клубның утырышларына туристик мәктәпнең танылган укытучыларын чакыру инде күркәм традициягә әверелде. Килгән кунаклар эшчәнлекләре, үзләре белән булган кызыклы вакыйгалар (ә алар аз түгел!), тәҗрибәләре белән уртаклашалар.

Күптән түгел генә узган шундый очрашуларның берсенә югары категорияле, кырык биш ел география һәм егерме ел икътисад фәннәрен укыткан укытучы, спорт мастерлыгына кандидат, чаңгы туризмы буенча СССР призеры **Хәмзә Килдеев** килде.

Ул үз гомерендә мәктәп укучылары белән унбиш тапкыр Кольск ярымутравы, Алтай (1980), Байкал (2009, 2012), Тянь-Шань (1970), Саян (2012), Кавказга (2011) походлар оештыра, алар вакытында төрле ачышлар ясый.

Хәмзә Килдеев үзенең укучыларын Уралга, Марий урманнарына, гипсның зур запаслары булган Юрьев мәгарәсенә алып бара. Галимнәр фикеренчә, әлеге запаслар дөньяда сигезенче урында тора икән. Ул сөйләгәннәрне тыңлап утырганда, үзебез дә шул җирләргә барган кебек булдык.

Шуңа басым ясыйсым килә: әлеге кеше күпсанлы походлар оештырып, укучыларында табигатькә, сәяхәткә карата мәхәббәт хисе, үзара ярдәм, дуслык төшенчәләрен гамәлдә аңлата һәм тәрбияли алган.

• Алар бездә укыган

# «Туган телдә укыту кирәкме?»

## дигән сорау кую – үзе зур гөнаһ»

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты



Шушы көннәрдә институтыбызга кунакка күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим килде. 1968 елда ук Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлаган Айдар ага бүгенге журфак студентларына уй-теләкләрен җиткерде.

Кемдер А.Хәлимне «Өч аяклы ат» повесте, «Татар вакыты», «Хунвэйбин» романнары авторы буларак белә. Авторның әлеге әсәрләре татар әдәбиятының яңа бер казанышы итеп кабул ителде. Кемгәдер әдипнең драматургиясе ошый. Безгә, булачак журналистларга, Айдар Хәлим публицистик эшчәнлеге белән аеруча якын һәм кызыклы.

Шулай да әдәбиятка ул шагыйрь буларак килеп керә. Аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Әмма кайсы гына өлкәдә иҗат итмәсен, Айдар ага һәрвакыт милли мәнфәгатьләрне яклап, үз халкының газиз улы буларак чыгыш ясый. Милли мәсьәлә – аның гомерлек иҗат темасы. Очрашуда без моның шулай икәнлегенә тагын бер кат инандык.

### А.Хәлим туган тел турында

«Туган тел, туган тел, дибез... Туган телне без ниндидер бер уенчык буларак кабул итәбез, аңа сәяси яктан да, фәнни яктан да нигезләнмәгән күренеш итеп карыйбыз. Туган тел – Җир йөзендә Алаһы Тәгалә кешелеккә биргән иң бөек байлык. Аны сорап алмыйлар һәм сораганга бирмиләр. Туган тел – кешенең тәне белән җаны туры килү. Гармония тән белән җан бергә булганда гына күзәтелә. Ә дошманнарыбыз тән белән җанны аерып, милләтне яшәүдән туктатырга ниятли. Туган тел – үзара аралашу чарасы гына түгел. Ул – милләтнең саулыгын, тазалыгын, аның физиологик барлыгын тәшкил итә торган байлык. Туган телдә белем алу баланың мөмкинлекләрен киңәйтә. Шуңа күрә дә балаларны туган телләрендә укытуны чикләргә омтылышны күзәтү бик авыр.

«Тугантелдәукытукирәкме?»дигән сорау кую, аны матбугатта күтәрү – үзе зур гөнаһ. Болай әйтергә дә ярамый.»

### А.Хәлим милләт турында

«Без – татарлар! 1941 елдагы сугышның ядрәләреннән яраланган кеше – татар кешесе, кардәшебез майор Гаврилов. Җир йөзендә моңарчы булмаган батырлык тарихы – 11 җәлилченең Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелүе. Бүтән халыкта мондый тарих бармы? Нишләп без моның белән горурланмыйбыз? Нишләп без аның милли, сәяси аспектларын күтәрмибез, өйрәнмибез? Аны бит ачарга кирәк. Бездә бит Тукай да ачылмаган, ә аның кебек даһи шагыйрь Җир йөзендә юк. Безнең әле бүгенгәчә дә аңа тиешле бәяне биреп бетерә алганыбыз юк...»

А.Хәлим бүгенге шартларда рухи чолганыштан чыгуның бер генә юлын күрә: ул да булса, туган тел. Әдип фикеренчә, аны үстерү кирәкми, чөнки ул кишер дә, кәбестә дә түгел. Бары тик туган телдә сөйләшергә генә кирәк! А.Хәлим очрашуга килгән һәркемне Ана телебездә сөйләшергә, милләтнең лаеклы улкызлары булырга чакырды.

Мондый бай иҗади һәм тормыш тәҗрибәсе булган шәхесләрне, «аяклы тарих»ларны белергә кирәк, минемчә. Ә аны күреп, аралашып белү мөмкинлеге – безнең өчен икеләтә бәхет.

***P.S.*** *А.Хәлим укырга кергән заманда Хрущев гуманитар юнәлеш буенча югары белем алу вакытын 5 елдан 4кә калдыра. Айдар ага да шушы бәхетле чорга эләгеп кала һәм уку йортын 4 елда тәмамлап чыга. Баксаң, бүген без дә әкренләп шушы системага кайтып барабыз. Тарих, чыннан да, кабатлана икән ул...*

• Халык җәүһәрләре

# «Йолдызлы» экскурсияләр

**Гөлфиназ НӘБИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Сезнең «Йолдызлы экскурсия»дә булганыгыз бармы? Ә менә миңа андый бәхет тәтеде Г.Тукай әдәби музеенда узган Халыкара театр көненә багышланган бу чараны Г.Камал театры актеры Фәнис Җиһанша алып барды.

Музейга килеп керүгә, Фәнис абыйның аһәңле, көр тавышы каршы алды. Аның чыгышын яшьләр дә, олылар да бирелеп тыңлады. Фәнис абый Тукай белән таныштырды, ул заманда булган авырлыклар турында сөйләде, үзе белгән истәлекләр белән тамашачыны әдәбият, сәнгать диңгезенә алып керде, күңелне моң белән иркәләде. Күз алдына ап-ачык булып Тукай образы килеп басты. Аның турында бик күп яңа кызыклы мәгълүматлар белдем. Үземне музейда түгел, ә Печән базарында йөргән кебек хис иттем. Музейдагы экспонатлар безне бөек шагыйребез чорына алып кайтты.

«Ә менә хәзер сезнең янга Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская үзе чыгачак. Кайда син, Сәхипҗамал?» – диюгә, барысы да шаккатып тирә-юньне күзли башлады.

Арадан бер яшь туташ: «Мин монда», – дип Тукай белән Сәхипҗамалга бәйле истәлекләргә тукталды. Әйтерсең, безнең каршыда бөек актриса үзе басып тора иде.

Экскурсиядән соң, кичәнең икенче өлешенә күчтек. Монда яшь шагыйрьләр үзләренең иҗаты белән таныштырды. Булат Ибраһим, Рифат Сәлах, Йолдыз Миңнуллина, Рүзәл Мөхәммәтшин, Луиза Янсуар, Эльнар Байназаров кебек яшь талантларның табадан гына төшкән иҗаты беркемне дә битараф калдырмады. Алар Казан консерваториясе студентлары чыгышы белән үрелеп барды. Чыгышлардан соң, әдәбиятыбызның, сүз, җыр сәнгатебезнең киләчәге якты, өметле икәненә тагын бер кат инандым.

Г.Тукай әдәби музеенда күп төрле мәдәни чаралар – әдәби музыкаль кичәләр, мәдәният әһелләре белән очрашулар, яңа китаплар белән танышу кичәләре, музей бәйрәмнәре, мастер-класслар бик еш уза. Фәнис Җиһанша белән узган экскурсия – «Йолдызлы экскурсия» проектының дәвамы. Фәнис Җиһанша – проектның дүртенче кунагы. Айга бер тапкыр музейда күренекле замандашларыбыз – мәдәният һәм сәнгать әһелләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре,



матбугат һәм төрле оешма вәкилләре, галимнәр һәм спортсменнар – Татарстан йолдызлары экскурсия уздыра. Мондый проектларның бик вакытлы икәне, халыкның шундый рухи ризык бирә торган чараларга сусаганлыгы күренә. Фәнис Җиһанша белән очрашуда залның шыгрым тулы булуы нәкъ шул хакта сөйли дә.

• «Тарихи» очрашулар

# Тарих һәм хакыйкать

Материалны **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде

Безнең күз алдыбызда инде берничә тапкыр Россия, Татарстан тарихлары яңадан язылды. Тарих объектив фәнме яисә ул сәяси элитаны канәгатьләндерүгә генә корылган мифлар җыелмасымы? Бу сорауларга җавапны UNIVERSMOTRI.RU каналы алып баручысы Ленар Мифтахов КФУ профессоры, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев белән бергәләп эзли.

**– Искәндәр Аязович, сезнең өчен тарих объектив фәнме, юкмы?**

- Тарих – минем яшәү рәвешем, дисәк тә ялгыш булмас, чөнки мин профессиональ тарихчы һәм бөтен гомерем шушы фән белән бәйләнгән. Студентлар белән беренче мәртәбә очрашкач, мин аларга тарихның нәрсә икәнлеген аңлатырга тотынам. Тарих – бик сәер әйбер. Бер караганда, ул фән дә түгел кебек , тарих – ул үткән, кайчандыр булган вакыйгалар. Аларны инде үзгәртеп тә, бизәп тә, кичерәйтеп тә булмый. Икенче яктан караганда, тарих – үткәннәрне аңлатырга омтылу.

«Тарихны белү нигә кирәк?» дигән сорауга үткәндәге ялгышларны кабатламас өчен, дигән киң таралган җавап бар. Әмма үткәндәге ялгышларны яңадан кабатлап булмый. Чөнки ул инде булган һәм башка булмаячак. Тарихның уникальлеге дә, күркәмлеге дә аның кабатланмас булуында. Шулай да тарихтан сабак алып була. Чөнки тарих – ул безнең биографиябез. Мин һәрвакыт тарихны кеше биографиясе белән чагыштырам. Үзенең биографиясен белмәгән кеше тормышта югалып калачак. Шуның кебек үк, тарихын белмәгән һәм хөрмәт итмәгән халык та югалачак, бүгенгесен дә, киләчәген дә төзи алмаячак.

**- Димәк, сезнеңчә, тарих – объектив әйбер?**

- Үткән, булган хәл итеп карасак, объектив. Әмма, икенче яктан, үткән һәм безнең аның турында нәрсә белүбез арасында үзенең мавыгулары, проблемалары, кызыксынулары, симпатияләре, антипатияләре булган КЕШЕ – үткәннәрне үзенчә интерпретацияләүче тарихчы шәхесе тора. Без тарихны турыдан-туры түгел, ә бары тик тарихчылар интерпретациясендә генә күрә алабыз. Бу уңайдан тарих – субъектив дисциплина. Һәр тарихчы объективлыкка омтылырга тиеш, әмма ул моңа беркайчан да ирешә алмаячак. Гомумән, тарих белән дә шулай: ул объективлыкка омтыла, әмма һәрвакыт билгеле бер дәрәҗәдә субъектив булып кала бирә.

**- Төрле халыклар тарихы белән чагыштырып караганда, сезнеңчә, татар тарихы идеаль объективлыкка якынмы?**

- Әлбәттә, юк. Теләсә кайсы тарих идеаль объективлыктан ерак. Тарихның асылын аңлатып бирә торган мондый гыйбарә бар: «Тарих – үткәнгә әверелдерелгән сәясәт». «Тарихны җиңүчеләр яза» дигәне дә бар әле. Тарихны, чыннан да, бүгенге заман торышына карап язалар.

**- Татар – үз вакытында яулап алынган милләт. Яулап алынган милләтнең тарихы объектив була аламы, сезнеңчә?**

- Мин мондый глобаль бәя бирмәс идем. Миңа калса, безнең азмы-күпме объектив тарих язу өчен шартларыбыз бар. Чын мәгънәсендә объектив тарихны язып та булмыйдыр, чөнки аны кешеләр яза. Безгә үткәннән калган бердәнбер хакыйкать – ул тарихи чыганаклар. Алар узган вакыйгаларны чагылдыра. Шуларга таянырга кирәк.

**- Татар тарихын ничек күрәсез? Аның аша нинди сабак алып булыр иде?**

- Тарих сабаклары, миңа калса, шактый зур һәм мөһим. Тарихыбызда җитәрлек дәрәҗәдә гыйбрәтле мизгелләр күп булган. Без дәүләтчелегебезне югалту сәбәпләрен төгәл белергә тиешбез, дип саныйм. Бу бит Явыз Иванның гаскәри һәм сәяси планда көчлерәк булуы аркасында гына килеп чыкмаган. Казан ханлыгын югалтуда безнең дә гаебебез бар. Без моның һәрберсен ачык аңларга һәм бу вакыйгаларның киләчәккә сабак булырга тиешлеге хакында онытмаска бурычлы.

**- Татарстанның хәзерге чорын татар тарихындагы нинди чор белән чагыштырыр идегез?**

- Миңа калса, чорларны чагыштыру мөмкин дә, урынлы да түгел. Татарлар өчен иң фаҗигале булып, XVI гасыр урталарыннан алып XVIII гасыр урталарына кадәрге чор санала. Бу вакытта милләт, дәүләтчелеген югалтканлыктан, шок хәлен кичерә. Аннан ул, яулап алынган милләт буларак, әкренләп яңа шартларда яшәүгә күнегә һәм аякка баса башлый. Икътисади, социаль, мәдәни нигез барлыкка килә, Исламга караш үзгәрә. Боларның һәммәсе татар халкын Ренессанс юлына чыгара. Милләт, чын мәгънәсендә, үсеп китә һәм бу Россия империясе белән идарә итүчеләр өчен көтелмәгән хәл булып чыга. Әмма, кызганыч, бу чор озакка сузылмый. Татар тарихында иң нәтиҗәле чор – 19 гасыр ахыры – 20 гасыр башы. Бу чорда татар мәдәнияте үсеше өчен, иң беренче чиратта, материаль нигез барлыкка килә. Татар меценатлары милли газета-журналлар, театр, мәктәпләр үсешенә зур акчалар корбан итәләр. Милли үзаңны, милли мәдәниятне үстерү өчен, шәхси милеккә карата ачык төгәл позиция булдыру, шәхси милекне хөрмәтли белү кирәк. Шул чагында тора-бара шәхси милекләре зур булган татарлар арасында акчаны үзең белән алып китеп булмавын аңлаучылар табылып, алар милләт файдасына эшли башларга мөмкин. Әмма бу бик катлаулы мәсьәлә.

● Таныш бул!

# Без җаваплы да, шаян да!

**Айзилә БАТРХАНОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Ни генә әйтсәгез дә, студент еллары иң күңелле һәм истә кала торган вакыт. Моңа, әлбәттә, мин үзем студент булгач инандым. Аеруча КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында белем алучы студентларның тормышы кызыгырлык.



Укудан тыш, яшьләр төрле күңелле чараларда катнашалар: иҗат белән шөгыльләнүчеләр «Әллүки» берләшмәсенә йөри, «Илһамлы каләм» конкурсында, «Шигъри Сабантуй»да катнаша, «Мизгел» яшьләр театрында уйный. Җырга мәхәббәте булганнар «Ал Зәйнәбем» һәм Фатыйма Әхмәдиева җитәкчелегендәге вокаль ансамбльгә йөриләр. Шаулап-гөрләп «Яшьлек» бию ансамбле эшләп килә.

Күптән түгел Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә өр-яңа «Tatar team» КВН командасы оешты. Яшь команда сәхнәгә чыгарга да өлгермәде, бөтен татар КВН лигасын шаккаттырды. Нәтиҗәләр дә таң калырлык. Өч ай эчендә «Tatar team» өч җиңүгә иреште. Яр Чаллыда узган татар лигасының ярымфиналында, «Сәләт» лигасында беренчелекне бирмәделәр. «Афәрин»нән башка сүз юк!

Институтыбызның беренче татар КВН командасы студентлар теләге белән барлыкка килде. Бу төркемдә барлыгы 10 катнашучы, барысы да шаян, иҗади, сәләтле. Мондый яшьләребез булганда, һичшиксез, татар юморы алга китәчәк.

Төркемдәшем Ләйсән Шәрәфетдинованы институтта гына түгел, хәтта университет күләмендә белмәгән кеше юктыр. «Джордж Байрон» командасының «Иң яхшы артист»ы исеменә лаек булган кызыбыз «Tatar team»да да уйный. Ләйсән үзе: «Мин бит татар кызы, татар филологиясендә укыйм! Татар сәнгатен, татар юморын без үстермәсәк, бу эшкә кем алыныр? Уенга килгәндә, башланганчы күңел әллә кайларга омтыла, канда адреналин ташый. Ә уеннан соң шундый позитив хисләр! Шатланабызкуанабыз! «Без бөтенесен дә төгәл һәм дөрес эшләдек!» дигән уй белән өйгә кайтып караватка авабыз!» – ди ул. Ничек кенә булмасын, бу – рәхәт ару, җиңүдән соң бәхетле халәт!

Уңыш буш урында гына барлыкка килми. Моның өчен тир түгәргә, зур тырышлыклар куярга кирәк. «Tatar team» командасы да, һәр көн диярлек дәресләрдән соң калып, бергә җыелып, мәзәкләр уйлый. Ә аларны театральләштереп уйнау исә икенче мәсьәлә.

«Командабызның оешуында, зур сәхнәгә чыгып, урыннар яулавыбызда Роберт абый (Роберт Исламов) белән Әнвәр абыйның (Әнвәр Айвазовский) рольләре бик зур. Алар сәхнәдә үзеңне дөрес тотарга, кызык итеп уйнарга өйрәтәләр. Дус кызларым, кастингта катнаш дигәч, барып карарга булдым. Алдылар! КВН тормышына тиз арада кереп киттем. Миңа «Tatar team»да уйнавы бииииик ошый. Андагы атмосфера, яңа танышлар, дуслар – болар барысы да искиткеч зур, шәп, кызыклы дөнья! – дип сөйләп китте Гөлия Имамова. Чыннан да, КВН тормышына кереп киткән кеше гомергә шул позитив халәттә яши. Көндәлек тормышта да алар һәрнәрсәне уен-көлкегә боралар, һичкайчан күңел төшенкелегенә бирелмиләр. Гөлия моның ачык мисалы.

10 катнашучының өчесе егетләр: Илназ, Ильяс, Нуршат. Исемнәре җисемнәренә туры килеп торган буегетләрсүзгәбиктапкыр. Күп миниатюраларның герое, «Мин – алып баручы» конкурсы җиңүчесе Илназ Сибгатуллин да КВНга карата фикерләре белән уртаклашты: «Татар филологиясендә КВН командасы барлыкка килүгә без бик сөендек. Ниһаять, үзебезнең сөйләм осталыгын, театраль мөмкинлекләребезне күрсәтә алабыз. Команда яшь булса да, без бик зур нәтиҗәләргә ирештек! Бу безнең өчен зур дәрәҗә!»

Мондый сәләтле яшьләр булганда, татар юморының киләчәге бик өметле дип саныйм. Иң мөһиме, безнең юмор – телевизорда күреп өйрәнгән, «билдән түбән» мәзәкләр түгел. «Tatar team» – юмористик гаилә, безне бер-беребездән башка күз алдына китереп тә булмый. Киләчәктә яшь команданы яңадан-яңа уеннар, җиңүләр көтә.

«Tatar team», без синең белән горурланабыз, сиңа җан атабыз!

● Тәнгә - мунча, җанга - юк

# Сатыла торган «белем»

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Университет тирәсендә кәгазьләр өләшүче промоутерларга әллә ни игътибар итмәскә өйрәнеп беттем инде. Гадәттә, алар тоттырып киткән «листовка»ларны беренче чүп чиләгенә ташлыйм. Тик «диплом, курс эшләрен «бишле»лек язып бирәбез, килегез!» – дигән язуны күргәч, кызыксынып киттем. Мин дә бит диплом эшен язу белән мәшгуль.

## «Диплом» базары

Өйгә кайту белән, Интернетка кереп, диплом һәм курс эшләрен сатып алу турында берәр кызык мәгълүмат эзләргә керештем. Аларны кайда саталар? Интернетта әзер эшләр бармы? Мондый «белем» күпме тора? Фәнни хезмәтләр сата торган оешмалар фикеренчә, курс һәм диплом эше язып уздырган вакыт – әрәмгә киткән вакыт. Тормышның кадерле мизгелләрен бушка уздырмыйм дисәң, аларга мөрәҗәгать ит, янәсе. Моның өчен темаңны сайлап, Казандагы дистәләгән белем «сатучы» оешманың берсенә бара аласың. Аларның эшләү асылы нидә булуын белер өчен, мин дә «вакытны бушка уздырырга теләмәүчеләр» рәтенә керергә булдым.

Курс һәм диплом эшләрен вуз укытучылары эшли икән. Аны башкару вакыты фәнни хезмәтнең авырлыгына карый. Бәясе дә шуңа карап исәпләнә. Курс эше, кимендә, 1600 сум тора. Ә диплом эшенең бәясе вузга карый, КФУ, мәсәлән, кыйммәтле вуз булып санала, шуңа күрә анда укучы студентлар диплом эшен сатып алырга теләсә, кимендә 12 мең сум белән хушлашачак. Фәнни хезмәт «антиплагиат» системасы аша үтәчәк. Текст Интернеттан гына алынмаганмы – әлеге система шул сорауга җавап бирә.



Ә закон бу фирмаларга эшләргә рөхсәт бирәме? Юрист Руслан Гатауллин менә нәрсә ди: «Юридик яктан барысы да законлы. Бу оешмалар үз эшләрен тәкъдим итә, ә аларга мөрәҗәгать иткән кеше сатып ала. Аларны җаваплылыкка бары тик салым түләмәгән өчен генә тартырга мөмкин. Тик моннан да бик җиңел юл белән котылып була: дөрес һәм яхшы лицензия ясап. Моннан соң инде кемдер студент өчен курс яки диплом эшен яза дип дәлилләү мөмкин түгел. Чөнки бу оешмалар: «Без аларга әдәбият тупларга, план төзергә булышабыз», – дип әйтә алачаклар.

## «Бишле» аласың килсә

Хәзерге вакытта диплом, реферат, курс эшләрен башкаручы оешмалар бик күп. Танышларым арасында мондый фирмаларга мөрәҗәгать итүчеләр бар. «Укытучыны ышандыру өчен, лекция яки китаптан берәр фикерне кертәсең дә яхшылап әзерләнәсең. Шуннан «бишле» синеке дип әйтергә дә була», – дигән фикердә «текә» студентлар. Тик акчаны һавага очырганнар да юк түгел. Фирмага мөрәҗәгать итеп, акчасын түлиләр, эшне алабыз дигәндә генә оешма юкка чыга.

## Үзем язам

Курс һәм диплом эшләрен, төннәр буе йокламыйча, үз тырышлыклары белән язучылар да бар әле. Моны сораштыру да дәлилли. Студентларның якынча өчтән икесе фәнни хезмәтләрне үзләре яза. Мин дә 4 ел буе бөтен фәнни эшләрне үзем әзерләдем, диплом эшен дә үзем язам. Башкача була да алмый дип уйлыйм. Чөнки әлеге хезмәтләр булачак һөнәребезнең асылын аңларга булыша.

Ә белемне сатып алырга маташкан яшьләрдән киләчәктә нинди белгеч чыгачак? Без дә кайчан булса да ата-аналар булырбыз. Кызыбыз яки улыбыз: «Әти, әни, син ничек укыдың?» – дип сораса, «Сабыем, барлык фәнни эшләрне дә сатып алдым», – дип җавап бирергә оят булмасмы?

● Сәнгать

# Язны бергәләп үткәрик!

**Ильмира КАМАЕВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Иҗат коллективының уңышлары һәрвакыт аның чыгышларында чагыла. Чын йөрәктән яраткан тамашачысы өчен эшләгәндә генә хезмәтенең нәтиҗәләре күренә.

Казан университетының татар Халык хоры – тамашачылар өчен иҗат итә торган коллективларның берсе. Менә 47 ел дәвамында Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе **Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллин**, университетның төрле факультетларында укучы студентларны үз канаты астына туплап, аларны иҗат диңгезендә йөздерә. Шәкертләрендә җыр-моңга мәхәббәт уятып кына калмыйча, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, яшәү мәгънәсе, тормышта үз урыныңны табу серләре белән дә уртаклаша.

Тыйнак кына иҗат белән шөгыльнүче әлеге коллективның уңышлары шактый. Чебешләрне көзен саныйлар, дигән гыйбарәгә каршы килеп, әлеге коллектив иҗатына еллык нәтиҗәне язын ясый. Быелгы яз да искәрмә түгел. Шул уңайдан, хор коллективы газета укучыларны һәм, гомумән, җыр-моң сөючеләрне үзенең чыгышларына көтеп кала!

Беренче концерт **12 апрель** көнне **16 сәгатьтә** дә Бауман урамында урнашкан рәссам **Константин Васильев галереясендә узачак**. «Безнең яз» дип исемләнгән йомгаклау концерты исә **25 апрель** көнне **18 сәгатьтә Казан университетының төп бинасында Актлар залында булачак**.

Быелгы язны Казан университетының татар Халык хоры чыгышлары белән хозурланып каршы ал!

DARELFONYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.